СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**7 апрель 2016 ел** **№ 43**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Арча район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында кушымтада бирелгән Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча муниципаль районы
Советының
07.04. 2016 ел карары белән
**РАСЛАНДЫ**

# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынулары барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

Хәбәр вазифаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр рәвешендә язма рәвештә рәсмиләштерелә (алга таба - хәбәрнамә).

3. Муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүче) 1 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Арча муниципаль районы башлыгына 2 нче кушымтада каралганча форма буенча төзелгән хәбәрнамә җибәрә.

5. Вәкаләтле орган рәисе вәкиллекле орган рәисе урынбасарына 3 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән хәбәрнамәне җибәрә.

6. Арча муниципаль районы башлыгы, муниципаль район вәкиллекле органы рәисе, рәисе урынбасары, башкарма комитет җитәкчесе, Арча муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына кергән мөрәҗәгатьләр карау өчен Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаны биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә (алга таба - Комиссия) тапшырыла.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында Комиссия хәбәрнамәләр җибәргән затлардан аларда бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алырга һәм

билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә хокуклы.

7. Хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилләнгән нәтиҗә әзерләнә.

Хәбәрнамәләрне алдан карау барышында алынган хәбәрләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар Комиссия утырышына тапшырыла, ул Комиссиягә хәбәрнамәләр кергән көннән алып җиде эш көне эчендә уздырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гарызнамәләр, хәбәрнамәләр, бәяләмәләр һәм башка материаллар җибәрелгән очракта, муниципаль район башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисенә, рәис урынбасарына, Арча муниципаль районының башкарма комитеты яисә җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесенә хәбәрнамәләр кергән көннән алып 45 көн эчендә Комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.

8. Комиссия хәбәрнамәләрне карый һәм Комиссия турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә алар буенча карарлар кабул итә, һәм кабул ителгән карарны муниципаль район башлыгына, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе урынбасарына, башкарма комитет җитәкчесенә, Арча муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесенә җибәрә.

9. Муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, рәис урынбасары, башкарма комитет җитәкчесе, Арча муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан Комиссия карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан шәхси кызыксынучанлык мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерергә мөмкин дип танырга;

в) хәбәрнамә җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яисә) җайга салу чаралары үтәлмәгәнлеген танырга.

10. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «б» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль район башлыгы, муниципаль районның вәкиллекле органы рәисе, урынбасары, башкарма комитет җитәкчесе яисә Арча муниципаль районының башка җирле үзидарә органы җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чараларын күрә йә хәбәрнамә җибәргән затка шундый чаралар күрергә тәкъдим итә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктындагы «в» пунктчасында каралган карар кабул ителгән очракта, муниципаль район башлыгы, муниципаль район вәкиллекле органы рәисе, рәисе урынбасары, Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе яисә җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе

Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылык чараларын күрәләр.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яис
ә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка
килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

______________________________
(танышу турында тамга)

_______________________________________
(эш бирүче вәкиленә)

_______________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: _________________________________________________________________

__________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________

__________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ________________________________________________________

__________________________________________________________________

әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим).

"____"_______________ 20___ел

_____________________________________________________________________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының

жирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яис
ә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка
килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

______________________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасы Арча район Советы рәисе

______________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында

# ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ________________________________________________________________

________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________

________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________________

________________________________________________________________

әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим (ниятләмим) .

"____"__________ 20__ел ____________________________________________________________

(хәбәрнамә җибәрүче затның имзасы) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләр,
муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар
тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яис
ә китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка
килү турында хәбәр итү тәртибе хакында
Нигезләмәгә 3 нче кушымта

______________________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасы Арча район Советы рәисе урынбасары

______________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфа)

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китергән яки китерергә мөмкин шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
ХӘБӘРНАМӘ

Вазыйфаи бурычны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесен ассызыкларга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүнең нигезе булган хәлләр: ________________________________________________________________

________________________________________________________________

Шәхси кызыксынучанлыгы йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вазыйфаи бурычлар: ____________________________________________

________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ______________________________________________

________________________________________________________________

Әлеге хәбәрнамәне караганда Татарстан Республикасы ________ муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятлим.

"____"______________ 20 ел,

________________________

________________________

(хәбәрнамәне җибәрүче затның
имзасы)